Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл
җирлеге Советы

**8 номерлы КАРАР**

Балыклы-Чүкәй авылы 2019 елның 13 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында 15.04.2019 ел, №63-ФЗ «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2015 елның 15 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 30 октябрендәге 15 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 17 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3.2 пунктының 12 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2) 3.2 пунктның 11 абзацында «1 ноябрьгә кадәр» сүзләрен «31 декабрьдән дә соңга калмыйча»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Иске Арыш авылы, Үзәк урамы, 23в, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 1 нче йорт, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://ribnaya керү

slobodа.tatarstan.ru həм» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы " Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башлыгы А.М.Нуртдинова